ГЛАВА
МЕНЗЕЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНЗӘЛӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

28.10.2025 г.Мензелинск № 50

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Башлыгының 11.03.2015 № 18 «Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Советының муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәр, милек һәм милек характерындагы йөкләмәләр турында мәгълүматлар тәкъдим итү тәртибен раслау турында, шулай ук Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Советының муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан керемнәр, чыгымнар, милек һәм милек характерындагы йөкләмәләр турында мәгълүматлар тәкъдим итү турында» карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясенең 10.07.2023 № 286-ФЗ «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законының 13 статьясы 4 пункты, Россия Федерациясенең 01.04.2022 № 90-ФЗ «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законының 5 статьясы 1 пункты нигезендә, карар чыгарам:

1. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы башлыгының 2015 елның 11 мартындагы № 18 «Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Советының муниципаль хезмәт урыннарына дәгъва кылучы гражданнарның керемнәре, милекләре һәм милек характерындагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар, шулай ук Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Советының муниципаль хезмәткәрләренең керемнәре, чыгымнары, милекләре һәм милек характерындагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар бирү турында Нигезләмәне раслау турында» карарга түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 16 пунктның 2 абзацында «яки аларның тулы булмаган яки дөрес булмаган мәгълүматлар бирүе» сүзләрен «үз чыгымнары турында мәгълүматлар, федераль законнар белән билгеләнгән очраклардан тыш, тулы булмаган мәгълүматлар бирү, яки алдан ук дөрес булмаган мәгълүматлар бирү» сүзләре белән алыштырырга, «яки үзләренең хатыны (ире) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында мәгълүматларны бирмәү яки тулы булмаган яки дөрес булмаган мәгълүматлар бирү» сүзләрен «яки үзләренең хатыны (ире) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында мәгълүматларны бирмәү, федераль законнар белән билгеләнгән очраклардан тыш, тулы булмаган мәгълүматлар бирү, яки үзләренең хатыны

(ире) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында алдан ук дөрес булмаган мәгълүматлар бирү» сүзләре белән алыштырырга;

1.2. 6 пунктның в подпунктында «, акцияләр» сүзен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Башлык А. Ф. Сәлахов